**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан»

В целях реализации статей $13^3$ и $18^1$ Федерального закона от 25 июля 2002 года № 115-ФЗ «О правовом положении иностранных граждан в Российской Федерации» **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 февраля 2014 года № УП-217 «О Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2014 года № УП-1065) следующие изменения:

а) преамбулу изложить в следующей редакции:

«В целях обеспечения проведения в Республике Татарстан дальнейшей работы по повышению благосостояния населения, сокращению неформального рынка труда и преодолению негативных тенденций в экономике, а также координации работы по определению потребности в привлечении в Республику Татарстан иностранных работников, в соответствии со статьями $13^3$ и $18^1$ Федерального закона от 25 июля 2002 года № 115-ФЗ «О правовом положении иностранных граждан в Российской Федерации» и постановлением Правительства Российской Федерации от 12 сентября 2013 года № 800 «Об утверждении Правил подготовки предложений по определению потребности в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы, утверждению квоты на выдачу иностранным гражданам приглашений на въезд в Российскую Федерацию в целях осуществления трудовой деятельности, а также квоты на выдачу иностранным гражданам, прибывающим в Российскую Федерацию на основании визы, разрешений на работу» **постановляю**:»;

б) в пункте 4:

абзац третий изложить в следующей редакции:

«по ежегодному определению потребности Республики Татарстан в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы, а также формированию на ее основе предложений от Республики Татарстан в установленном законодательством порядке;»;

дополнить абзацами следующего содержания:

«по внесению в Республиканскую межведомственную комиссию по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан предложений о приостановлении на определенный период выдачи патентов на территории Республики Татарстан, а также об установлении запрета на привлечение хозяйствующими субъектами, осуществляющими деятельность на территории Республики Татарстан, иностранных граждан, осуществляющих трудовую деятельность на основании патентов, по отдельным видам экономической деятельности;

по размещению результатов рассмотрения заявленной потребности работодателей в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы, в открытом доступе на официальном сайте Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».»;

в) пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6. Рекомендовать органам местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан, Республиканской трехсторонней комиссии по регулированию социально-трудовых отношений ежегодно принимать участие в информировании работодателей о порядке определения потребности в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы, и подготовки предложений об увеличении (уменьшении) размера потребности в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы.»;

г) в Положении о Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан:

пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Республиканская межведомственная комиссия по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан (далее – Комиссия) образована в целях обеспечения согласованных действий органов исполнительной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти в Республике Татарстан (далее – территориальные органы федеральных органов исполнительной власти) и органов местного самоуправления по повышению благосостояния населения, сокращению неформального рынка труда и преодолению

негативных тенденций в экономике, а также участия в работе по определению потребности Республики Татарстан в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы.»;

пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2. В своей деятельности Комиссия руководствуется Конституцией Российской Федерации, Федеральным законом от 25 июля 2002 года № 115-ФЗ «О правовом положении иностранных граждан в Российской Федерации», постановлением Правительства Российской Федерации от 12 сентября 2013 года № 800 «Об утверждении Правил подготовки предложений по определению потребности в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы, утверждению квоты на выдачу иностранным гражданам приглашений на въезд в Российскую Федерацию в целях осуществления трудовой деятельности, а также квоты на выдачу иностранным гражданам, прибывающим в Российскую Федерацию на основании визы, разрешений на работу», иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.»;

в пункте 3:

абзац двенадцатый изложить в следующей редакции:

«рассмотрение заявок работодателей, заказчиков работ (услуг) (далее – работодатели) о потребности в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы, для замещения вакантных и создаваемых рабочих мест либо выполнения работ (оказания услуг) в предстоящем году (далее – заявка работодателя на предстоящий год), заявок работодателей об увеличении (уменьшении) размера потребности в привлечении иностранных работников, прибывающих в Российскую Федерацию на основании визы, для замещения вакантных и создаваемых рабочих мест либо выполнения работ (оказания услуг) (далее – заявка работодателя об увеличении (уменьшении) потребности);»;

дополнить абзацем тринадцатым следующего содержания:

«рассмотрение предложений Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан о приостановлении на определенный период выдачи патентов на территории Республики Татарстан, а также об установлении запрета на привлечение хозяйствующими субъектами, осуществляющими деятельность на территории Республики Татарстан, иностранных граждан, осуществляющих трудовую деятельность на основании патентов, по отдельным видам экономической деятельности.»;

абзацы тринадцатый и четырнадцатый считать соответственно абзацами четырнадцатым и пятнадцатым;

д) в составе Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и

использования иностранных работников в Республике Татарстан (далее – Комиссия):

вывести из состава Комиссии С.В. Чепуштанова;

ввести в состав Комиссии Шакирова Фаршата Сагитовича – временно исполняющего обязанности начальника Управления Федеральной миграционной службы по Республике Татарстан (по согласованию).

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Временно исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
30 июля 2015 года
№ УП-688

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның $13^3$ һәм $18^1$ статьяларын гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында халыкның тормыш шартларын яхшырту, рәсми булмаган хезмәт базарын киметү һәм икътисадта тискәре күренешләрне бетерү буенча алга таба да эш алып баруны тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасына чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү ихтыяҗын билгеләү эшен координацияләү максатларында, «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның $13^3$ һәм $18^1$ статьялары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү ихтыяҗын билгеләү, чит ил гражданнарына Россия Федерациясенә хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру максатларында керү өчен бирелә торган чакыруларга квотаны, шулай ук чит ил гражданнарына эшкә рөхсәт кәгазьләрен бирүгә квотаны раслау буенча тәкъдимнәр әзерләү кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 елның 12 сентябрендәге 800 номерлы карары нигезендә **карар бирәм**:»;

б) 4 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүдә Татарстан Республикасы ихтыяҗларын билгеләү, шулай ук аның нигезендә, законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасыннан тәкъдимнәр әзерләү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә патентлар бирүне билгеле бер чорда туктатып тору турында, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекләрен тормышка ашыручы хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан хезмәт эшчәнлекләрен патентлар нигезендә тормышка ашыручы чит ил гражданнарын икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча җәлеп итүне тыю турында тәкъдимнәр кертү;

Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүдә эш бирүчеләрнең игълан ителгән ихтыяҗларын карап тикшерү нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында һәркем файдалана алырлык итеп урнаштыру».»;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы республика комиссиясенә ел саен эш бирүчеләргә Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүдә ихтыяҗны билгеләү һәм Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүдә ихтыяҗ күләмен арттыруга (киметүгә) кагылышлы тәкъдимнәр әзерләү тәртибе хакында мәгълүмат бирүдә катнаширга тәкъдим итәргә.»;

г) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәдә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) халыкның тормыш шартларын яхшырту, рәсми булмаган хезмәт базарын киметү һәм икътисадта тискәре күренешләрне бетерү буенча алга таба да эш алып баруны тәэмин итү, шулай ук Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүдә Татарстан Республикасы ихтыяҗын билгеләү эшендә катнашу буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының (алга таба – федераль башкарма хакимият

органнарының территориаль органнары) һәм җирле үзидарә органнарының килешенгән гамәлләрен тәэмин итү максатларында төзелде.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү ихтыяҗын билгеләү, чит ил гражданнарына Россия Федерациясенә хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру максатларында керү өчен бирелә торган чакыруларга квотаны, шулай ук чит ил гражданнарына эшкә рөхсәт кәгазьләрен бирүгә квотаны раслау буенча тәкъдимнәр әзерләү кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 елның 12 сентябрендәге 800 номерлы карарына, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.»;

3 пунктта:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүчеләрнең, эшләргә (хезмәт күрсәтүләргә) заказчыларның (алга таба – эш бирүчеләр) киләсе елга вакантлы һәм булдырыла торган эш урыннарын биләү яисә эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә ихтыяҗлары турында гарызнамәләрен (алга таба – киләсе елга эш бирүче гарызнамәсе), эш бирүчеләрнең киләсе елга вакантлы һәм булдырыла торган эш урыннарын биләү яисә эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә ихтыяҗ күләменең артуы (кимүе) турында гарызнамәләрен (алга таба – эш бирүченең ихтыяҗның артуы (кимүе) турында гарызнамәсе) карап тикшерү;»;

түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә патентлар бирүне билгеле бер чорда туктатып тору турында, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекләрен тормышка ашыручы хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан хезмәт эшчәнлекләрен патентлар нигезендә тормышка ашыручы чит ил гражданнарын икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча җәлеп итүне тыю турында тәкъдимнәрен карап тикшерү.»;

д) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан С.В. Чепуштановны чыгарырга;

Комиссия составына Шакиров Фәршат Сәгыйть улын – Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча) кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 30 июль
№ ПУ-688